РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ЮЛБАТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422077, Республика Татарстан,
с. Юлбат, ул. Г.Тукая, 57
тел. (84362) 43-7-22

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЮЛБАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422077, Татарстан Республикасы,
Юлбат авылы, Г.Тукай урамы, 57 йорт
тел. (84362) 43-7-22

e-mail: Ulbat.Sab@tatar.ru

21.02.2025 № 4

РЕШЕНИЕ КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советының 29.09.2021 №21 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге чикләрендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 28.12.2024 №540-ФЗ Федераль законына, Саба районы Прокуратурасының 14.02.2025 №02-08-02-2025/Прдп127-25-20920031 протестына нигезләнеп, Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге чикләрендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәне раслау хакында» 29.09.2021 елгы №21 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге чикләрендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.5. пунктның икенче абзацында «мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү, урынга барып тикшерү» сүзләрен «үзара хезмәттәшлексез контроль (күзәтчелек) чараларын»сүзләренә алмаштырырга.»;

1.2. 11.пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

1.3. 5.10.пунктның 5.10.3. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.10.3. Документлар буенча тикшерү уздыру срогы ун эш көненнән артмаска тиеш.

Документлар буенча тикшерү үткәрү срогын исәпләү контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан тикшереп торылучы затка җибәрелгән вакыттан алып шул чорга туктатып тора:

- документлар буенча тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны таләптә күрсәтелгән документларны контроль (күзәтчелек) органына тапшырган вакытка кадәр тапшыру таләпләре;

- контрольдә тотылучы зат тапшырган документлардагы хаталарны һәм (яисә) каршылыкларны ачыклау турында йә бу документлардагы белешмәләрнең контроль (күзәтчелек) органындагы документлардагы һәм (яисә) дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда алынган белешмәләргә

туры килмәве турында контроль (күзәтчелек) органы мәгълүматларына һәм кирәкле язма күрсәтелгән язма аңлатмаларны контроль (күзәтчелек) органына тапшырганчыга кадәр аңлату.»;

1.4. 5.10. пунктның 5.10.9. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.10.9. Планнан тыш документар тикшерү «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6, 8 пунктлары нигезендә прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин.»;

1.5. 5.11. пунктның 5.11.3. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«5.11.3. Планнан тыш күчмә тикшерү «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.2020 №248-ФЗ Федераль законның 1 өлешендәге 3, 4, 6, 8 пунктлары, 57 статьясындагы 3 өлеше һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин.»;

1.6. 5.12. пунктның 5.12.3. пунктчасында икенче абзацны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ulbat адресы буенча рәсми рәвештә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Юлбат авыл җирлеге Башлыгы Т.Р. Шәмсиев